ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 2 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

“14) махсус инвестиция контракты имзаланган елга кадәрге календарь елның 1 числосыннан башлап һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан башлап исәпкә куелган махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен яңа булдырылган яисә сатып алынган мөлкәткә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән сәнәгать сәясәте өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы яисә “Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында” 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сәнәгать тармакларында махсус инвестиция контрактларын төзүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башка федераль башкарма хакимият органы аша белдерелгән Россия Федерациясе белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә аның тарафыннан “Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы аша белдерелгән Татарстан Республикасы бер як буларак билгеләнгән махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автотранспорт чаралары

җитештерүче оешмалар. Ташлама күрсәтелгән мөлкәт исәпкә алынган айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап, әмма махсус инвестиция контракты төзелгән айның 1 числосыннан иртәрәк түгел, махсус инвестиция контракты гамәлдә булу срогына, ләкин 10 елдан күп булмаган вакытка бирелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 02 декабрь
№ 88-ТРЗ